**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

## ПОСТАНОВЛЕНИЕ

## КАРАР

«14» февраль, 2024 ел

№ 84

«Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннар һәм гомуми мөлкәтне җайлаштыру чаралары планын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Инвалидлар ихтыяҗларын исәпкә алып, күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне урнаштыру чаралары планын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2023 елның 15 декабрендәге 968 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Карарга кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Инвалидларның торак урыннарын һәм күпфатирлы йортларда муниципаль торак фонды составына керүче инвалидлар яшәгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәтне, шулай ук инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалидлар өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итеп, хосусый торак фондын урнаштыру чаралары планы.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында http:/ www.-pestreci.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р.Шәйхетдиновка йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе — В.И.Никитин